РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОИКШУРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

422066, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Старая Икшурма,ул.Ленина,д.17
тел.8 (84362) 41-6-47

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИСКЕ ИКШЕРМӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422066, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Иске Икшермә авылы, Ленин урамы, 17 йорт
тел.8 (84362) 41-6-47

e-mail: sik.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
16.09.2022

КАРАР
№25

Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлегенең Башкарма комитетының 06.04.2020 №16 карары белән расланган Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләүне үткәрү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 15.06.2022 ел, №1081 РФ Хөкүмәте Карары нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге башкарма комитетының “Иске Икшермә авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм бәяләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 6 апрелендәге 16 номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районының Иске Икшермә авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.1.3 пунктында «муниципаль программаларның структур элементлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 3.3 пунктның икенче абзацында «муниципаль программаларның структур элементлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 3.3 пунктның өченче абзацын киләсе редакциядә бәян итергә:

"бирелгән ташламаларга түләүчеләрнең ихтыяҗы, ул ташламаларга хокуклы түләүчеләр саны нисбәте һәм ташламаларны куллану хокукына ия булган түләүчеләр саны яки 5 еллык чорда түләүчеләрнең гомуми саны нисбәте белән характерлана.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Саба муниципаль районының Иске Икшермә авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ikshurma адресы буенча бастырып чыгарырга һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы А. И.Биккинин